РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023 г. г. Альметьевск № 106

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының XV бүлеге нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына 1 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителгән үзгәрешләр кертү проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү комиссиясе составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга:
Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составы;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашу тәртибе;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында 4 нче кушымта нигезендә ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.
5. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында (Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт, 325 нче кабинет) 2023 елның 12 маенда 15.00 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

Комиссиягә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт

шәһәрендә ачык тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә нигезендә Уставка үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуны һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт шәһәр Советының
2023 елның 29 мартындагы
106 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

1) 6 статьяның 1 елешендә:

а) 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;»;

б) 36 пунктта «федераль закон нигезендә» сүзләрен естәргә;

2) 11 статьяда:

а) 7 елешнең икенче абзацында «Шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба - сайлау комиссиясе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 7.1 елеш естәргә:

«7.1. Җирле референдумда яшәү урыны Шәһәр чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә яшерен тавыш биргәндә катнаша.»;

3) 12 статьяда:

а) 4 өлешнең икенче абзацында «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, «Татарстан Республикасы Сайлау кодексында» билгеләнгән тәртиптә шәһәр сайлау комиссиясе вәкаләтләре йөкләнергә мөмкин булган Әлмәтнең сайлау комиссиясе яисә территориаль сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 елешнең алтынчы абзацында «Шәһәр сайлау комиссиясендә, яисә Әлмәт шәһәре территориаль сайлау комиссиясендә, аңа Шәһәр сайлау комиссиясе вәкаләтләре йөкләнергә мөмкин» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 13 статьяда:

а) 5 елештә «Шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 елештә «Шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга, «сайлау комиссиясе утырышлары» сүзләрен «сайлау комиссиясе утырышы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 өлештә «Шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «Сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 26 статьяда:

а) 2 елешнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 елешнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)

сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 елештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәисен) сүзләренә алмаштырырга;

г) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрөн «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

д) 9 елешне үз кечен югалткан дип танырга;

6) 28 статьяның 1 елешендә «, ә ул булмаганда - Шәһәр сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен тешереп калдырырга;

7) 29 статьяның 1 елешендә:

а) 16 пунктны тешереп калдырырга;

б) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) сайлау комиссиясе составына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү;»;

8) 36 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.1 елеш естәргә:

«1.1. Шәһәр Советы депутаты вәкаләтләре депутат җитди сәбәпләрсез Шәһәр Советының барлык утырышларында алты ай рәттән булмаган очракта Шәһәр Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

9) 38 статьяның 1 елешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

10) 42 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

11) 45 статьяның 1 елешендә:

а) 3 пунктның унберенче абзацында «федераль закон нигезендә» сузләрен естәргә;

б) 5 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итә, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү ечен шартлар тудыра;»;

12) 46 статьяның 4 елешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) Шәһәрнең контроле һәм аның Советы тарафыннан хисап тоту;

2) Шәһәр Советына үз эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм шәһәр Башкарма комитеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Шәһәр Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисаплар тапшыра;

3) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен хәл итү буенча Шәһәр башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итә.»;

13) 50 статьяда:

а) 2 елешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 елештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгын (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

14) 54 статьяны үз кечен югалткан дип танырга;

15) 63.1 статьяда:

а) 1 елешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

16) 64.1 статьяда:

а) 1 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 елештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 елештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 11 елешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

з) 14 елештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

17) 68 статьяның 5 елешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары ечен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.»;

18) 90 статьяның 2 елешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр уставы, Шәһәр Советының Шәһәр Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турындагы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм әлеге Устав нигезендә рәсми басылып чыкканннан (халыкка җиткергәннән) соң, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Россия Юстиция министрлыгы порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» (http://pravo-minjust.ru, http://pravo-минюст.рф) урнаштырганнан соң үз кеченә керәләр. Шәһәр башлыгы теркәлгән шәһәр Уставын, шәһәр Советының шәһәр Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турындагы карарын, муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү елкәсендә «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 елешендә каралган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында Шәһәр Уставы, муниципаль хокукый акт турында белешмәләр кертү хакында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 елешендә каралган федераль башкарма хакимият вәкаләтле органы территориаль органыннан кергән кеннән алып җиде кен эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт шәһәр Советының
2023 елның 29 мартындагы
106 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Баһманов И.Р. | Әлмәт шәһәре башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Парфилова Н.В. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты |
| 3. | Мусин Р.Ф. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты, бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 4. | Шәйхетдинова Ф.А. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе |
| 5. | Закиров Р.З. | Бердәм сайлау округы буенча Әлмәт шәһәр Советы депутаты |
| 6. | Әфләтунова Р.Е. | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| 7. | Ханнанова Ә.Б. | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт шәһәр Советының
2023 елның 29 мартындагы
106 номерлы карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алу тәртибе

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре Уставы таләпләре нигезендә гражданнарның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышуда һәм аларның тәкъдимнәрен исәпкә алуда катнашуын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советына кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада түбәндәге адрес буенча кертелә: Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт:

| №№ п/п | Пункт, пунктча | Проект тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Нигез | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.О., адресы, телефоны, эш урыны (уку), имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты «Альметьевский вестник» газетасында басылып чыкканнан соң ачык тыңлаулар уздырылган көнгә кадәр кабул ителә.

3. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча: Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт яисә почта аша (конвертта “Устав турында” дигән тамга белән), шулай ук 39-01-31 факс буенча, ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре һәм ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хатлар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча комиссиягә тапшырыла.

5. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр проектында булган үзгәрешләргә карата гына кертелә һәм федераль законнар таләпләренә туры килергә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының башка нигезләмәләре белән каршылыклар яисә ярашмаучанлыклар булдырмаска һәм Шәһәр Уставы нигезләмәләрен бертерле шәрехләүне тәэмин итәргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставындагы үзгәрешләр кертү проекты, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарылган гражданнар тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә ачык тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмә нигезендә ачык тыңлауларда фикер алышырга тиеш.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт шәһәр Советының
2023 елның 29 мартындагы
106 номерлы карарына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында ачык тыңлаулар уздыру тәртибе

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә ачык тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы проекты, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы тарафыннан Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында Карар проекты аны кабул итү мәсьәләсен Әлмәт шәһәр Советы караган кенгә кадәр 30 кеннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка чыгарылырга) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турындагы карары бастырыла.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре уставын шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында тегәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибен рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы проекты яисә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча ачык тыңлаулар, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын тегәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

4. Ачык тыңлаулар уздыру турында карар басылып чыккан кеннән алып аларны уздыру кененә кадәр шәһәр халкы халык алдында тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм тезәтмәләр җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм тезәтмәләр ачык тыңлауларда

катнашучыларга җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставы проекты яисә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып комиссия тора.

6. Халык тыңлауларында шәһәр башлыгы, шәһәр башлыгы урынбасары, шәһәр Советының даими комиссияләре рәисләре рәислек итә ала. Рәислек итүче ачык тыңлауларны ача, ачык тыңлаулар мәсьәләсен (мәсьәләләрен), тыңлаулар үткәрү тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, тыңлаулар үткәрү инициаторларын күрсәтә.

7.Рәислек итүче ачык тыңлауларны үткәрү инициаторлары вәкаләтле кешегә, шулай ук чыгыш ясау хокукына ия булган җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга сүз бирә. Чыгышлар чираты комиссия тарафыннан теркәлгән гаризалар бирү чираты белән билгеләнә.

8.Тыңлауларда катнашучылар үз тәкъдимнәрен тешерергә һәм (яки) башка җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тәкъдим иткән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.

9. Ачык тыңлаулары вакытында беркетмә алып барыла. Ачык тыңлауларында катнашучыларның ачык тыңлаулар барышында килгән барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре ачык тыңлаулар секретаренә җибәрелә.

10. Беркетмәгә ачык тыңлаулар рәисе кул куя.

11. Ачык тыңлаулар беркетмә нигезендә, эш кеннәрендә исәпләнгән 3 кен эчендә, ачык тыңлаулар уздырылган кеннән башлап, ачык тыңлаулары нәтиҗәләре турында нәтиҗә тезелә.

12. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм ачык тыңлаулар уздырылган кеннән башлап, 5 кен эчендә басылып чыгарга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

Шәһәр Башлыгы — «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» — Т.Д. Нагуманов